РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОКАЗЕЕВСКОГО**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**ИСКЕ КАЗИЛЕ**
**авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Центральная, 7,д. Караталга, 422834
тел. (8-834-77)30-4-39, факс: (8-834-77) 30-4-39
ОКПО 93064642 , ОГРН 1061672003425
ИНН/КПП 1622004595/162201001

Үзәк урамы, 7, Каратал авылы, 422834,
тел(8-834-77)30-4-39. , факс: (8-834-77)30-4-39
ОКПО 93064642, ОГРН 1061672003425
ИНН/КПП 1622004595/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**15 декабрь 2018 года** **№ 10**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 26 сентябрендәге “Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 6 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 26 сентябрендәге 6 санлы карары белән расланган Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5нче бүлекнең 5.4нче пунктында:

1) 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) мөрәҗәгать итүченең дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган

документларны яисә мәгълүматны гамәлгә ашыру яисә гамәлләрне башкару таләп итү;”;

2) түбәндәге эчтәлекле 10 пунктчасы белән тулыландырырга:

“10) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартканда дөрес булмавы һәм (яки) булмавы күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүмат таләп итү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш;”;

1.2. 5нче бүлекне түбәндәге эчтәлекле 5.13, 5.14 пунктлар белән тулыландырырга:

5.13. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенә һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.14. Шикаять мөрәҗәгать итүчегә җавапта канәгатьләнергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.”.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;
2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Каратал авылы, Күпер урамы, 5;

3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14; шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Җитәкче И.Х. Сәгдиев